**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 февраль № 102

г. Казань

«Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәяләр кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында

«Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәле камилләштерелүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 8 май, ФЗ-83 нче Федераль закон нигезендә, идарә итүнең икътисадый методларын камилләштерү, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген, төзелеш тармагын үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының эшләп торучы «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе» дәүләт учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Төзелеш һәм архитектура буенча Татарстан Республикасының дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесен (алга таба – автоном учреждение) оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Автоном учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы башкара дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына:

60 көн эчендә автоном учреждение уставын расларга һәм аны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

автоном учреждение уставын дәүләт теркәвенә алган көннән 30 көн эчендә автоном учреждениенең күзәтү советы составын расларга;

автоном учреждение өчен дәүләт йөкләмәсен аның уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлек нигезендә билгеләнгән тәртиптә ел саен расларга.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына автоном учреждение уставын дәүләт теркәвенә алганнан һәм автоном учреждениенең

күзәтү советы составын раслаганнан соң 30 көн эчендә элек «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе» дәүләт учреждениесенә беркетелгән, автоном учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне, оператив идарә хокукында автоном учреждениегә беркетергә.

5. Автоном учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасында территориаль планлаштыру документлары проектларына һәм проектлау документларына дәүләт экспертизасы үткәрү һәм аларны раслау тәртибе һәм Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 2 август, 391 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территориаль планлаштыру документлары проектларына һәм проектлау документларына дәүләт экспертизасы үткәрү һәм аларны раслау тәртибе һәм Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча ведомствога карамаган дәүләт экспертизасы идарәсе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 2 август, 391 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында территориаль планлаштыру документлары проектларына һәм проектлау документларына дәүләт экспертизасы үткәрү һәм аларны раслау тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2009 ел, 13 май, 307 нче.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\102.doc